| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**03.04.2026** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№1150** |

2026 елга Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләрендә салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2026 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2026 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2025 елның 08 декабрендәге 777/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен 2026 елга Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләрендә салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен расларга:

1.1. салым салынырга тиешле гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 2 756 628,00 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 5 513 256,00 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 8 269 884,00 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 11 026 512,00 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 13 783 140,00 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 16 539 768,00 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 19 296 396,00 сум

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 87 562,77 сум;
1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 87 562,77 сум;
1.2.3. өч кешедән һәм аннан да күбрәк торган гаилә өчен – 87 562,77 сум

2. «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә, торак урыннарына мохтаҗлар буларак

исәпкә куелганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

**2026 елга салым салынырга тиешле һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү МЕТОДИКАСЫ**

1. **Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар хакы исәп-хисап күрсәткече**

**СЖ = НП*РС*РЦ, биредә**

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасына карап торак урын сатып алуның базар хакы исәп-хисап күрсәткече;
НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләрендәге торак урыннарының 1 кв. м.уртача күрсәткеченә туры килә торган торак урынның бер квадрат метры мәйданының уртача исәпләнгән базар бәясе (2026 ел башына – 153 146,0 сум).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 153 146*18*1 = 2 756 628
б) ике кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 153 146*18*2 = 5 513 256
в) өч кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 153 146*18*3 = 8 269 884
г) дүрт кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 153 146*18*4 = 11 026 512
д) биш кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 153 146*18*5 = 13 783 140
ж) алты кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 153 146*18*6 = 16 539 768
з) җиде кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 153 146*18*7 = 19 296 396

2. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме**

**$ПД = 0{,}7 \cdot СЖ \cdot ПС / (1-(1+ПС)^{-КП}) / (0{,}25 \cdot РС)$, биредә**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасына карап торак урын сатып алуның базар хакы исәп-хисап күрсәткече;
ПС – кредит буенча айлык процент ставкасы (16% / 12);
КП -кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);
РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;
0,25 — гаиләнең гомуми айлык кереме белән кредит буенча түләү нисбәте

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7*2 756 628*0,013 / (1-(1+0,013)-240) / (0,25*1) = 105 075,32

б) ике кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,7*5 513 256*0,013 / (1-(1+0,013)-240) / (0,25*2) = 105 075,32

в) өч  һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,7*8 269 884*0,013 / (1-(1+0,013)$^{-240}$) / (0,25*3) = 105 075,32

г) дүрт  һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,7*11 026 512*0,013 / (1-(1+0,013)$^{-240}$) / (0,25*4) = 105 075,32